РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМАНАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРМАНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ул. Татарстан д.15«а», с.Урманаево,
Азнакаевский район, 423311

Татарстан урамы, йорт 15 “а”, Урманай авылы
Азнакай районы, 423311

Тел./факс(8-85592)4-30-49/4-30-49; E-mail Azn.Urman@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 16 » ноябрь 2020 ел № 03

2021 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Урманай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

**Карары:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында Үрта урам 14 йорт адресы буенча урнашкан Беренче Май бистәсе мәдәният йортында 2020 елнын 27 ноябрендә 10.00 сәгать 00 минутта Беренче Май торак пункты Югары урам 1 йорттан 33 нче йортка, Түбән урамы 1 йорттан 35 нче йортка, Урта урамы 1 йорттан 12 нче йортка кадәр теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында 2021 елда гражданнарның узара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май торак пунктында 2021 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә;

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2021 елда Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);

- Авыл җирлеге территорияләрен төзекләндерүне оештыру (Беренче Май бистәсендә ике телдә язылган урам исемнәре һәм йортлар күрсәткечләрен сатып алу (әзерләү);

- Беренче Май поселогында юлларны кардан чистарту;

- Беренче Май т. п. мөселман һәм православие зиратларында контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу, киртәләр ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез салу, киртәләр кую);

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

.

Рәис А.И.Закиров